**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 1 ноябрендәге 4583 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 7 декабрендәге 7835 номерлы «Хәрби хәрәкәт ветераннарының, хәрби хезмәт инвалидларының, һәлак (вафат) булган хәрби хәрәкәт ветераннары, хәрби хезмәт инвалидлары гаиләләренең торак мәсьәләләре буенча, гражданнарны Социаль ипотека программасы буенча торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тану мәсьәләсе буенча, яшь гаиләләрне «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасында катнашучылар итеп тану мәсьәләсе буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты каршындагы торак комиссиясен оештыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гражданнарның торак мәсьәләләре комиссиясенең нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 7 декабрендәге 7835 номерлы «Хәрби хәрәкәт ветераннарының, хәрби хезмәт инвалидларының, һәлак (вафат) булган хәрби хәрәкәт ветераннары, хәрби хезмәт инвалидлары гаиләләренең торак мәсьәләләре буенча, гражданнарны Социаль ипотека программасы буенча торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тану мәсьәләсе буенча, яшь гаиләләрне «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасында катнашучылар итеп тану мәсьәләсе буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты каршындагы торак комиссиясен оештыру турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 28 мартындагы 1680 номерлы, 2015 елның 24 апрелендәге 1883 номерлы, 2016 елның 24 августындагы 3551 номерлы, 2018 елның 16 октябрендәге 5383 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге 6555 номерлы, 2020 елның 18 маендагы 1405 номерлы, 2020 елның 21 июлендәге 1951 номерлы, 2021 елның 12 июлендәге 1710 номерлы, 2023 елның

23 октябрендәге 3187 номерлы, 2024 елның 12 мартындагы 817 номерлы, 2024 елның 16 августындагы 3376 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. преамбуланы түбәндәге редакциядә бирергә:

«Гамәлдәге торак законнарын, 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы «Ветераннар турында»гы федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 мартындагы 153 номерлы «“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык уңайлы торак, коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының “Гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү” процесслы чаралар комплексын гамәлгә ашыру кысаларында Дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында»гы, 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы «“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында»гы карарларын, 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы «Гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль яллау килешүләре буенча торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы «Гражданнарның аерым категорияләренә федераль бюджеттан бүленә торган субвенцияләр хисабына субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау турында»гы, 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы «“Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында”гы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча алга таба күреләсе чаралар һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү турында»гы карарларын гамәлгә ашыру максатыннан **карар бирәм**:»;

1.2. карарның исемендә һәм 1, 2 пунктларында, 1 номерлы кушымта исемендә «Хәрби хәрәкәт ветераннарының, хәрби хезмәт инвалидларының, һәлак (вафат) булган хәрби хәрәкәт ветераннары, хәрби хезмәт инвалидлары гаиләләренең торак мәсьәләләре буенча, гражданнарны Социаль ипотека программасы буенча торак урыннар алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тану мәсьәләсе буенча, яшь гаиләләрне «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасында катнашучылар итеп тану мәсьәләсе буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты каршындагы торак комиссиясе» сүзләрен тиешле килешләрдә «Казан шәһәре Башкарма комитеты

каршындагы торак комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 2 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.4. әлеге карарның кушымтасын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 7 декабрендәге 7835 номерлы карарының 2 номерлы кушымтасы дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 1 ноябрендәге
4583 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитеты каршындагы**
**Торак комиссиясе турында нигезләмә**

1. Казан шәһәре Башкарма комитеты каршындагы Торак комиссиясе (алга таба – Комиссия) түбәндәге категорияләргә караган гражданнарны торак белән тәэмин итү мәсьәләләрен карап тикшерү максатыннан төзелә:

- хәрби хәрәкәт ветераннары;
- хәрби хезмәт инвалидлары;
- һәлак булган (вафат булган) хәрби хәрәкәт ветераннарының, хәрби хезмәт инвалидларының гаиләләре;
- Казан шәһәре Башкарма комитетында торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торучы Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнар һәм аларга тиңләштерелгән затлар (махсус куркыныч бүлекчәләрендәге гражданнар);
- даими яшәү өчен торак урыннары белән тәэмин ителмәгән һәм Казан шәһәре Башкарма комитетында торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә торучы, билгеләнгән тәртиптә күчеп кайтырга мәҗбүр дип танылган гражданнар;
- Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән китүче (чыгып киткән), Казан шәһәре Башкарма комитетында торак урынга мохтаҗ буларак исәптә торучы гражданнар;
- республиканың социаль ипотека программасы кысаларында торак урыннар сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ гражданнар;
- «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләр;
- социаль яллау килешүе буенча торак урыннарга мохтаҗлар исәбендә торучы гражданнар.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Торак кодексы, 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы «Ветераннар турында»гы, 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә

радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында», 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар агызу нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында», 2002 елның 25 октябрендәге 125-ФЗ номерлы «Ерак Төньяк районнарыннан һәм аларга тиңләштерелгән җирләрдән китүче гражданнарга бирелә торган торак субсидияләре турында», 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»гы федераль законнар, Россия Федерациясе Югары Советының 1991 елның 27 декабрендәге 2123-1 номерлы «“Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында” РСФСР Законы йогынтысын тарату турында»гы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 мартындагы 153 номерлы «“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының “Гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү” процесслы чаралар комплексын гамәлгә ашыру кысаларында дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм тарату кагыйдәләрен раслау турында», 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы «“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык уңайлы торак белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында»гы карарлары, 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы «Гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль яллау килешүләре буенча торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы «Гражданнарның аерым категорияләренә федераль бюджеттан бүленә торган субвенцияләр хисабына субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау турында»гы, 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы «2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча алга таба күреләсе чаралар һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тортибен камилләштерү турында»гы карарлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

3. Комиссия Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән төзелә.

4. Комиссия утырышлары ихтыяҗ туган саен уздырыла һәм аларның эшендә Комиссия составының яртысыннан күбрәге катнашкан очракта хокуклы дип санала. Комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

5. Комиссиягә түбәндәгеләр йөкләнә:

- 1 пунктта күрсәтелгән гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ дип тануның шартларын, тәртибен һәм законлы нигезләрен аңлату эшләрен башкару;

- Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәптән төшерү;

- «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» процесслы чаралар комплексына (алга таба – процесслы чаралар комплексы, чара) кертү;

- процесслы чаралар комплексында катнашучы гражданнар арасында процесслы чаралар комплексын гамәлгә ашыру шартларын аңлату эшләрен башкару;

- гражданнар тарафыннан тапшырылган гаризалар һәм документлар нигезендә планлаштырыла торган елда дәүләт торак сертификаты алырга теләк белдергән гражданнар исемлекләрен, планлаштырыла торган елда социаль түләү алырга теләк белдергән, чарада катнашучы яшь гаиләләр исемлекләрен төзү;

- процесслы чаралар комплексын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы башкарма органына планлаштырыла торган елда федераль бюджет акчалары исәбеннән дәүләт торак сертификатын алырга теләк белдергән гражданнар исемлекләрен тапшыру;

- Татарстан Республикасының башкарма органына планлаштырыла торган елда социаль түләү алу теләген белдергән, чарада катнашучы яшь гаиләләрнең исемлеген тапшыру;

- Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан төзелгән субсидия алучыларның җыелма исемлегенә федераль бюджеттан субвенцияләр рәвешендә торак сатып алуга субсидияләр бирү юлы белән социаль ярдәм алу хокукына ия гражданнарны кертү;

- гражданнар тарафыннан торак сатып алуга субсидияләр алу хокукын раслау яки аларны субсидия алучыларның җыелма исемлегеннән чыгару;

- торак сертификатлары һәм субсидияләр алучы гражданнарны социаль ипотека шартларында торак сатып алу өчен исәпкә кую;

- гражданнарны социаль ипотека программасы буенча торак урыннар сатып алуда кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ дип тану;

- яшь гаиләне торак урынына мохтаҗ дип тану;

- «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасында катнашучы буларак торак сатып алуга социаль түләү ала торган яшь гаиләләр исемлегенә кертү;

- яшь гаиләләрне «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасында катнашучылар составыннан төшереп калдыру;

- торак урынына мохтаҗ буларак исәптә торучы гражданинга гомуми чират тәртибендә социаль яллау килешүе буенча торак урыны бирү.

6. Комиссия:

- үз утырышларында үз вәкаләтләренә кергән мәсьәләләрне карап тикшерергә;

- торак мәсьәләләре буенча вәкаләтләре чикләрендә карарлар кабул итәргә һәм аларны беркетмәләр рәвешендә рәсмиләштерергә;

- Казан шәһәре Башкарма комитетында торак шартларын яхшырту буенча исәптә торучы гражданнарның гаризаларын һәм шикаятьләрен карап тикшерергә хокуклы.

---